


2023 елнын 14-17 февральдә Казанда татар теле һәм әдәбияты буенча тобәкара олимпиада vтте. Чара РФ субъектларынын мәгариф идарәсе органнары белән тозелгән белем бирv олкәсендә хезмәттәшлек турында килешvләрне гамәлгә ашыру, туган (татар) телнен дәрәжәсен һәм укучыларнын белем дәрәжәсен кvтәрv, укучылар, татар теле һәм әдәбияты укытучыларына гамәли ярдәм кvрсәтv максатыннан уздырылган.
Олимпиадада Россиянен 28 тобә-геннән 8-11 сыйныфта укучы 187 бала - татар теле һәм әдәбияты буенча олимпиадаларнын топ этаплары жинvчеләре һәм призёрлары катнашкан.
15-16 февральдә Идел буе физик культура, спорт һәм туризм университеты базасында Педагог һәм остаз елына багышланган татар теле һәм әдәбияты буенча олимпиада, шулай ук сойләм туры (нәфис сvз) узган.      Бәйгечеләр арасында Мордовиядән 11 укучы булуы да аеруча соенечле. Алар - татар теле һәм әдәбияты буенча республика олимпиадасы жинvчеләре һәм призерлары. Укучылар белән бергә Казанга аларны бу житди сынау-га әзерләvче остазлары татар теле һәм әдәбияты укытучылары юлланды: Сания Спартак кызы Саляева (Рузаевка районы Татар Пешлә урта мәктәбе), Альфия Фатих кызы Муртазина (Ләмберә районы Татар Тавла топ мәктәбе), Фазия Фәрит кызы Боярова (Ләмберә районы Черемиш топ мәктәбе), Луиза Низаметдин кызы Смакаева (Ләмберә районы Кривозерье урта мәктәбе) торган группаны Кадошкино районы Латышовка авылы мәктәбенен татар теле һәм әдәбияты хормәтле укытучысы Светлана Равиль кызы Поташова житәкләде. Казанга юлланган тобәкнен ин кочле, тәжрибәле укытучылары бу коннәрдә укучылары очен борчылып, жан атып, терәк булып торган.
- Казанда безне бик жылы каршы алдылар. Барысы да югары дәрәжәдә оештырылган. Укытучылар очен аерым чаралар булуы да моһим. Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгынын Милли мәгариф идарәсе белгечләре һәм дәреслекләр авторлары белән очрашу да бик жанлы узды. Олимпиада кысаларында катнашучылар очен Казаннын истәлекле урыннары белән танышуны vз эченә алган мәдәни-экскурсия программасы, Г.Камал (Ай-гол Әхмәтгалиеванын «Капка») һәм К.Тинчурин (Г.Камалнын «Беренче театр») театрларында спектакльләр тамаша кылу каралган иде.
Бәйгегә килгәндә, безнен укучылар житди әзерлек белән килделәр. Моны Мәгариф министрлыгында сектор житәкчесе Гулия Фаргат кызы Мусина да билгеләп vтте. Укучыларыбызнын яхшы нәтижәләре шатландырды», - ди Латышовка мәктәбе татар теле һәм әдәбияты укытучысы, делегацияне житәкләгән Светлана Равиль кызы Поташова. - Татар теле һәм татар әдәбияты Регионара олимпиадасында Мордовия делегация вәкилләре барысы да лаеклы призерлар булдылар. Ижади конкурста да кем сәнгатьле шигырь укып, кем матур жырлап vзләрен сынатмыйча гел призлы урыннар яуладылар.
16 февральдә К.Тинчурин исемендәге Татар дәvләт драма һәм комедия театрында олимпиаданы ябу тантанасы vткән. Призерларнын исемнәре тvбәндә.
Кильдеева Дарина, Кадошкино районы Большие Поляны топ мәктәбе 8 класс укучысы (укытучылары - З.Х.Кильдеева); Исхакова Мәрьям, Ләмберә районы Кривозерье урта мәктәбе 8 класс укучысы (укытучысы Л.Н.Смакаева).
Муртазина Самира белән Айзятуллов Ильнур, Ләмберә районы Татар Тавла топ мәктәбе

9 класс укучылары (укытучылары А.Ф.Муртазина).
Харисова Энже, Ләмберә районы Аксён урта мәктәбе 10 класс укучысы (укытучысы А.Ш.Абдюшева).
Тумпарова Алсу белән Тумпарова Регина, Кадошкино районы Латышовка урта мәктәбе 11 класс укучылары (укытучылары С.Р.Поташова).
Мансурова Ильнара белән Курмакаева Карина, Ләмберә районы Черемиш топ мәктәбе 9 класс укучылары (укытучылары Ф.Ф.Боярова).
Кузикова Самира, Рузаевка районы Татар Пешлә урта мәктәбе 11 класс укучысы (укытучысы С.С.Саляева); Алькаева Римма, Ләмберә районы Пензятка урта мәктәбе 11 класс укучысы (укытучысы Р.М.Юмаева).
- Биремнәрне унышлы эшләп чыктым дип уйлыйм, эшемне «жинәм» дигән уй-ният белән тапшырдым. Биредә шулкадәр рәхәт моһит тудырылган иде: бар борчылуларым эреп китте.
Олимпиадага укытучым белән нык-лап әзерләндем. Иртән торып кабатлаган тел гармониясе темасы да эләкте»,- дип сойләгән олимпиада призеры тәжрибәле укытучысы Луиза Низаметдиновнага Ләмберә районы Кривозерье урта мәктәбе 8 класс укучысы Исхакова Мәрьям.
Тобәкара олимпиадада жинvче һәм призер исемен яулаучылар татар теле һәм әдәбияты буенча 21-24 нче апрельләрдә vтәчәк Халыкара олимпиадасында катнашачаклар.

**Наилә НАСЫРОВА**